.СОВЕТ
УТАР-АТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
*РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН*
ул.Кооперативная, д. 22, с. Утар-Аты,
Арский муниципальный район, 422017

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УТАР-АТЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Кооператив урамы, 22 йорт, Утар-Аты авылы,
Арча муниципаль районы, 422017

Тел. (84366)50-3-31, факс (84366)50-4-22. E-mail: Utat.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар-Аты авыл җирлеге башлыгы карары**

**22 март 2024 ел** **N 3**

**"Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар Аты авыл җирлегенең Югары Аты авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында" 2023 елның 22 ноябрнең 3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар-Аты авыл җирлегенең Югары Аты авылында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Арча муниципаль районы Утар Аты авыл җирлеге уставының 25 статьясына ярашлы рәвештә, Арча муниципаль районы Утар Аты авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы карар бирде:

1. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар Аты авыл җирлегенең Югары Аты авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 22 ноябрнең 3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар-Аты авыл җирлегенең Югары Аты авылында гражданнар җыенының беренче этабын Югары Аты авылы, Кооператив урамы, 22 йорт адресы буенча 2024 елның 06 апрелендә 16 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар Аты авыл җирлегенең Югары Аты авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 22 ноябрнең 3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар-Аты авыл җирлегенең Югары Аты авылында гражданнар җыенының икенче этабын Югары Аты авылы, Кооператив урамы, 22 йорт адресы буенча 2024 елның 06 апрелендә 17 сәгать 00 минутка билгеләргә.

3. Халык исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

1 нче этап: Кооператив, Мәктәп урамнарында яшәүчеләр;

2нче этап: Комсомол урамында яшәүчеләр.

4 «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар Аты авыл җирлегенең Югары Аты авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 22 ноябрнең 3 номерлы карарында гражданнар җыены соравын яңа редакциядә бәян итәргә:

« Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Утар – Аты авыл җирлеге Югары Аты авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1 нче группа инвалидлардан, 80 яшьтән узган граждакнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү ,шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (җирле әһәмияттәге юл-урам челтәренең йөрү өлешенең өслек һәм тигезләгеч катламнарын ясау өчен вак таш сатып алу,грейдер хезмәтләре өчен түләү);

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (Арча - Олы Әтнә төбәк юлы янында урнашкан чишмә территориясендә ремонт эшләре башкару);

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәсен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (юл-урам челтәрендә янмый торган лампочкаларны алыштыру өчен яктырткычлар сатып алу);

- каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыклары ясау, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү (Мәктәп урамы янындагы чүплекне рекультивацияләү);

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары составына кермәгән җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау (Аты елгасы аша Мәктәп урамы буенча җәяүлеләр кичүе өчен материаллар сатып алу)?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

5. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар Аты авыл җирлегенең Югары Аты авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 22 ноябрнең 3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар-Аты авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны ТР, Арча районы, Югары Аты авылы, Кооператив урамы, 22 йорт адресы буенча мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan ru веб-адреслары буенча бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Утар-Аты авыл җирлеге башлыгы Мөхәмәтгалиева А.Г.